**Татарстан Республикасы**
**Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

«26» мая **2025** ел № 121

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2013 елның 20 июлендәге 61 номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Күлле-Киме авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать тәртибен саклау буенча ирекле халык дружиналары турында Нигезләмәне раслау хакында» гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының 2015 елның 16 гыйнварындагы №4-ЗРТ «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» Законына, Әтнә районы прокуратурасының 2025 елның 31 гыйнварындагы №02-08-02-2025/Прдп44-25 номерлы протестына таянып, Күлле-Киме авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 2013 елның 20 июлендәге 61 номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Күлле-Киме авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә җәмәгать тәртибен саклау буенча ирекле халык дружиналары турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. Карар преамбуласында** «2005 елның 1 ноябрендәге №107-ЗРТ 'Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнар катнашуы турында'» сүзләрен «2015 елның 16 гыйнварындагы №4-ЗРТ 'Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында'» сүзләренә алыштырырга.

**1.2. Нигезләмәнең 2 нче статьясында** «2005 елның 1 ноябрендәге №107-ЗРТ Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнар катнашуы турында» сүзләрен «2015 елның 16 гыйнварындагы №4-ЗРТ 'Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында'» сүзләренә алмаштырырга.

**1.3. Нигезләмәнең 10 статьясының 2 пунктында** «Россия ЭЭМның "Биектау" муниципаль районы буенча "Әтнә" полиция бүлеге» сүзләрен «Әтнә районы буенча Россия ЭЭМ бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

**1.4. Нигезләмәнең 13 статьясының 2 пунктының 2, 3 подпунктларында** «Россия ЭЭМның "Биектау" муниципаль районы буенча "Әтнә" полиция бүлеге» сүзләрен «Әтнә районы буенча Россия ЭЭМ бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

**1.5. Нигезләмәнең 14 статьясының 4 пунктында** «ПБ» сүзләрен «Әтнә районы буенча Россия ЭЭМ бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

**1.6. Нигезләмәнең 18 статьясының 4 пунктында** “Биектау” Россия ЭЭМ (“Әтнә”) ПБ” сүзләрен «Әтнә районы буенча Россия ЭЭМ бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

**1.7. Нигезләмәнең 23 статьясының 1 пунктында** “Биектау” Россия ЭЭМ (“Әтнә”) полиция бүлекчәсе” сүзләрен «Әтнә районы буенча Россия ЭЭМ бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.

**1.8. Нигезләмәнең 23 статьясының 5 пунктында** «Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауда халыкның катнашуы турында» сүзләрен «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» сүзләренә алмаштырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы: Гәрәев Х.Х.